РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ КУКМОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

06.03.2026 Кукмара ш. № 135

Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2019 елның 07 ноябрендәге 617 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы муниципаль гомуми белем бирү оешмалары укучыларын тукландыруны оештыру тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә белем бирү турында» 2012 елның 29 сентябрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 37 статьясы, Татарстан Республикасы «Кукмара муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставының 47 статьясы нигезендә **карар бирәм:**

1. Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2019 елның 07 ноябрендәге 617 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы муниципаль гомуми белем бирү оешмалары укучыларын тукландыруны оештыру тәртибе турында нигезләмәгә, (Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2020 елның 2-октябрендәге 602 номерлы, 2023 елның 26 июлендәге 421 номерлы, 2025 елның 01 декабрендәге 666 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.3 пунктында:

унтугызынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «авыл җирендәге белем бирү учреждениеләре укучылары өчен: иртәнге аш – 10 сум 70 тиен, төшке аш – 52 сум 64 тиен, көнгә, ә Кукмара шәһәре чикләрендәге белем бирү учреждениеләре укучылары өчен: иртәнге аш – 10 сум 70 тиен, төшке аш – 61 сум 68 тиен, көнгә»;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

- Россия Эчке эшләр министрлыгының Кукмара районы буенча бүлеге хезмәткәрләренең (эшчеләренең) балаларын бушлай туклану белән тәэмин итү;

2. Әлеге карар 2026 елның 1 мартыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарны ТР хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында (http://kukmor.tatarstan.ru) урнаштырырга.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **А.Х. Гарифуллин**